СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 7-21 от «26» апреля 2023 г.

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмә хакында» 2012 елның 23 апрелендәге 4-12 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый нигезләмәсен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 8 маендагы № 83-ФЗ, «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011елның 7 февралендәге № 6-ФЗ федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2012 елның 23 апрелендәге 4-12 номерлы (28.03.2019 ел, №10-32 редакциясендәге үзгәрешләр белән) карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 17 статьясының 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8. Контроль-хисап органы тәкъдимен яисә күрсәтмәсен үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылуга китерә».;

1.2. Нигезләмәнең 17 статьясындагы 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтмәне үтәү срогы контроль-хисап органы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин бер тапкырдан да артык түгел.».

000019

1.3. Нигезләмәнең 17 статьясындагы 3 пунктында «күрсәтмә алынган көннән алып бер ай эчендә» сүзләрен «тәкъдимдә күрсәтелгән срокта яисә, әгәр срогы күрсәтелмәгән булса, аны алган көннән алып 30 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга, «карау» сүзен «үтәү» сүзенә алмаштырырга;
1.4. Нигезләмәнең 17 статьясындагы 1 пунктында «аларны карау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «ачыкланган» сүзеннән соң «бюджет һәм башка» сүзләрен өстәргә;
1.5. Нигезләмәнең 8 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда башка затларга карата. »;

1.6. Нигезләмәнең 8 статьясындагы 1 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. әлеге муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына тиешенчә кергән муниципаль район бюджеты, бюджет акчаларын куллануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген контрольдә тота;»;

1.7. Нигезләмәнең 8 статьясындагы 1 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) җирле бюджет хисабына салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук муниципаль гарантияләр һәм йөкләмәләр бирүнең законлылыгын бәяләү яисә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан җирле бюджет һәм муниципаль милектәге мөлкәт хисабына башкарыла торган килешүләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү;»;

1.8. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Муниципаль берәмлекнең тикшерү-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары вазыйфасына түбәндәге квалификация таләпләренә туры килүче Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә:
1) югары белем булу;
2) дәүләт муниципаль идарә, дәүләт муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эшләү тәҗрибәсе булу;
3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын, конституцияне (уставны), Россия Федерациясенең тиешле субъекты законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, тиешле муниципаль берәмлек уставын һәм вазыйфаи бурычларын үтәүгә карата башка муниципаль хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль һәм эксперт-аналитик чараларын уздыру өчен

тышкы дәүләт һәм муниципаль аудит (контроль) стандартларына гомуми таләпләрне белү.»;

1.9. Нигезләмәнең 3 статьясында «бәйсезлек» сүзеннән соң «ачыклык» сүзен өстәргә ;

1.10. Нигезләмәнең 7 статьясындагы 5 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"3) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булуы;".

1.11. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 2 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"4) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда яисә чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булуы;";

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль Советның регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П. Иванов